# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**21 ноябрь, 2025 ел** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Мәчкәрә авылында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Мәчкәрә авылында гражданнар җыены **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2026 елда Кукмара муниципаль районының Күкшел авыл җирлеге Мәчкәрә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- урам яктырту;
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- коеларны төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү;
- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын урнаштыру, ремонтлау;
- һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаганнары) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү;
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы

автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, ремонтлау;

- каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыкларын төзү, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Күкшел авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Хәмидуллин